ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 432-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 432-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2008-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.Р. Зарипов,
Л.Н. Рыбакова
тарафыннан кертелде

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^1$ статья. **Мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калуны, алардан файдалануны, аларны популярлаштыруны, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне), ачыкланган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавын тәэмин итәләр.»;

2) $10^2$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:

«17[1] статья. **Мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хокуклары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калуны һәм аларны популярлаштыруны, шул исәптән тиешле чараларны финанслауны, шулай ук мәдәни мирас объектлары турындагы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт саклавы вәкаләтләре тапшырылган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) дәүләт саклавы гамәлләрен финанслауны оештыруда катнашырга;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары гамәлгә куючылары булган китапханәләрнең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыруда катнашырга;

составына федераль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлешен һәм составына муниципаль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләтнеке булмаган өлешен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан музейлар белән үзара эшчәнлек аша саклап калуда һәм тулыландыруда катнашырга;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль милектәге һәм дәүләт циркларына хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләүне дә кертеп, яңадан техник җиһазландыру һәм капиталь ремонтлау гамәлләрен финанслауда катнашырга.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 4 өлешенә (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш); № 27 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын саклап калуны һәм аларны популярлаштыруны, шул исәптән тиешле чараларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауны, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт саклавы вәкаләтләре тапшырылган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы гамәлләрен финанслауны оештыруда катнашырга хокуклы.».

**3 статья**

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары гамәлгә куючылары булган китапханәләрнең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыруда катнашырга хокуклы.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

2023 елның 25 апрелендә үз көченә кергән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 14 апрелендәге 129-ФЗ номерлы Федераль законда Россия Федерациясе субъектларының түбәндәгеләргә катнашу хокукы каралган:

Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына ярдәм күрсәтергә;

Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан федераль яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калуны һәм аларны популярлаштыруны, шул исәптән тиешле чараларны финанслауны, шулай ук мәдәни мирас объектлары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына дәүләт саклавы вәкаләтләре тапшырылган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) дәүләт саклавы гамәлләрен финанслауны оештыруда катнашырга;

Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан федераль дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары гамәлгә куючылары булган китапханәләрнең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыруда катнашырга;

составына федераль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлешен һәм составына муниципаль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләтнеке булмаган өлешен Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан музейлар белән үзара эшчәнлек аша саклап калуда һәм тулыландыруда катнашырга;

Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан федераль милектәге һәм дәүләт циркларына хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләүне дә кертеп, яңадан техник җиһазландыру һәм капиталь ремонтлау гамәлләрен финанслауда катнашырга.

Моңа бәйле рәвештә «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының югарыда күрсәтелгән хокукларын билгеләү өлешендә тиешле үзгәрешләр кертү зарур.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.